ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 март 2021 ел № 1353

Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итүгә һәм яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәләрен булдырмауга юнәлдерелгән кичектергесез чаралар күрү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11 июлендәге 1032 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 декабрендәге 2963-р номерлы Боерыгы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7324 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре (алга таба – аренда Шартнамәсе) буенча аренда түләве күләмендә 2020 елның 1 апреленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп торуны түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирергә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының (алга таба – КУЭ субъекты) аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

2) кичектереп тору мөмкинлеге бирелә торган аренда түләүләренең суммасы арендатор тарафыннан тәкъдим ителгән срокта 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап, ләкин 2023 елның 1 гыйнварыннан соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкыр, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләве күләменең яртысыннан артмаган бертигез күләмдәге түләүләр белән түләнергә тиеш;

3) кичектереп тору сәбәпле, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибе һәм сроклары үтәлмәү белән бәйле башка җаваплылык чаралары (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый;

4) кичектереп тору мөмкинлеге бирелү сәбәпле, арендага бирүче тарафыннан арендатор түләргә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

5) кичектереп тору шартлары, аренда шартнамәсе буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзү датасына бәйсез рәвештә, аренда шартнамәсенә карата кулланыла.

1.1. Аренда түләве күләмендә аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору, әлеге карарның 1 пунктының 2-4 пунктчаларында күрсәтелгән шартларны үтәп, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага аренда Шартнамәсе буенча узган чор өчен аренда түләвен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган очракта, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертү турында карар кабул ителгәнче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы карары нигезендә һәм (яки) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 11 июнендәге 847 номерлы карары нигезендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар) белән төзелгән аренда Шартнамәсе буенча, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу чорына бирелә.

1.2. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә

хәл начараю шартларында аеручa зыян күргән Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы һәм аренда шартнамәсе буенча аренда түләвеннән азат итү рәвешендә 2020 елның апрель-июне өчен аренда түләве буенча ташлама бирелгән КУЭ субъектына, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән шартларны үтәгән очракта, 2020 елның 1 июленнән 2021 елның 1 гыйнварына кадәр чор өчен аренда түләве күләмендә аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелә.

1.3. Аренда шартнамәсе буенча аренда түләвеннән азат итү рәвешендә 2020 елның апрель-июне өчен аренда түләве буенча ташлама бирелгән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмага, әлеге карарның 1 пунктының 2-4 пунктчаларында күрсәтелгән шартларны үтәгән очракта, 2020 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу чорына аренда түләве күләмендә аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ